**Зур Сәрдек авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

15 ноябрь 2022 ел №19

# Карар

2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номеры Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге Уставына таянып, Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелә торган 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Кукмара шәһәре муниципаль берәмлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасын расларга
2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Зур Сәрдек авыл
җирлеге җитәкчесе Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1061675011276
ИНН 1623008627

Зур Сәрдек авыл җирлеге
Башкарма комитетының 15
ноябрьнең 19 номерлы карары
белән расланды

***2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү***

**ПРОГРАММАСЫ**

## 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасы паспорты

| | |
|---|---|
| **Программаның исеме** | 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү Программасы |
| **Программаның заказчысы:** | Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты |
| **Программаның максатлары:** | - Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү өчен иң уңайлы шартлар тудыру;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары санын арттыру;<br>- халыкны эш белән тәэмин итү һәм үзмәшгульлекне үстерү. |
| **Программаның бурычлары:** | - кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары саны арту;<br>- өстәмә эш урыннары булдыру, кече һәм урта бизнес белән мәшгульләр санының еллык артуы;<br>- продукцияне, эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне эшләп чыгаруның гомуми күләмендә кече предприятиеләрнең еллык өлеше арту;<br>- җирлек бюджетына кече һәм урта эшмәкәрлектән кергән салым керемнәре өлешен арттыру;<br>авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүдә ярдәм итү;<br>- кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм инфраструктурасын формалаштыру һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү;<br>кече эшмәкәрлеккә ярдәм инфраструктурасы кысаларында кече предприятиеләргә методик, мәгълүмати консультация, белем бирү һәм хокукый яктан ярдәм күрсәтү. |
| **Программа белән идарә итү** | Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты |

| | |
|---|---|
| **Программаны финанслау чыганаклары** | Җирлек бюджеты 6 мең сум, шул исәптән еллар буенча:<br>1) 2022 ел – 1,5 мең сум;<br>2) 2023 ел – 1,5 мең сум;<br>3) 2024 ел – 1,5 мең сум;<br>4) 20243 ел – 1,5 мең сум; |
| **Программаның төп башкаручылары** | Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге башкарма комитеты |
| **Программаның үтәлешен тикшерү** | Зур Сәрдек авыл җирлеге Советының даими комиссиясе |

**Программаның бүлекләре:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең торышын анализлау
2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү
3. Программаның социаль-икътисади нәтиҗәлелегенә көтелгән бәя
4. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре
5. 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасының төп чаралары

## 1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекнең торышын анализлау

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хуҗалык итүнең базар системасының аерылгысыз элементы булып тора. Базар икътисады алга киткән илләрдә кече эшмәкәрлек дәүләт икътисадының нигезе, хуҗалык үсешенең двигателе булып тора, чөнки бу теләсә кайсы җәмгыятьнең эшлекле тормышының иң динамик һәм сыгылмалы формасы.

Хуҗалык итүнең базар системасы шартларында кече һәм урта эшмәкәрлекнең аерым ролен түбәндәге факторлар билгели:

үз тормышын һәм лаеклы тормыш дәрәҗәсен мөстәкыйль тәэмин итүче һәм гражданлык җәмгыятенең тотрыкландыручы төп сәяси көче булган урта сыйныф өлешен арттыру;

кече һәм урта эшмәкәрлек секторында яңа эш урыннары булдыру өчен зур потенциал булу, җәмгыятьтә эшсезлек дәрәҗәсен һәм социаль киеренкелекне киметү;

халыкның төп массасының иҗтимагый психологиясенең һәм тормыш ориентирларының үзгәрүе;

кече һәм урта эшмәкәрлекнең сыгылмалылыгы һәм җитештерү структурасын тиз арада үзгәртеп кору, яңа технологияләрне һәм фәнни эшләнмәләрне оператив рәвештә булдыру һәм куллану сәләте.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече эшмәкәрлекне үстерү программасын эшләү һәм тормышка ашыру зарурлыгы туа.

Бүген җирлектә күпчелек Россия Федерациясе Хөкүмәте, Татарстан Республикасы һәм җирле үзидарә органнарының максатчан сәясәте нәтиҗәсендә нык күтәрелә торган бизнесны актив үстерү өчен барлык ресурслар да бар.

## 2. Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү проблемалары һәм аларны программа методлары белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлек шактый нык позициядә торуга карамастан, кайбер проблемалар элеккечә хәл ителмәгән булып кала бирә.

Авылда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеге үсешен тоткарлаучы факторлар булып түбәндәгеләр тора:

- инвестиция ресурсларыннан файдалану кыенлыгы, кредит ресурсларының һәркем файдалана алырлык булмавы фонында үз финанс чараларың җитмәве;
- гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр турында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мәгълүматы аз булу, административ каршылыклар һәм эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашырганда хакимият органнарының төгәл регламентлары булмау;

Эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары тарафыннан карарлар кабул итүне һәм гамәлгә ашыруны таләп итә торган проблемалар:

- кече эшмәкәрлек субъектларының социаль җаваплылыгы югары булмау (ялланган хезмәткәрләр белән хезмәт мөнәсәбәтләрен рәсмиләштермәү, хезмәткә түләү фондын киметү һәм аны «конверт» формасында түләү, мәҗбүри пенсия иминияте һәм социаль иминиятләштерү турындагы законнарны үтәмәү);

Авылда кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба да даими үстерү һәм булган каршылыкларны урыннарда мәгълүмати, белем бирү, консультация, финанс юнәлешләрендә комплекслы һәм адреслы ярдәм күрсәтү юлы белән аны үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру буенча максатчан эш нигезендә, эшлекле элемтәләрне һәм кооперацияне җайга салу юлы белән, шулай ук эшмәкәрләрдә коллектив ихтыяҗ туарга мөмкин булган башка аспектларда ярдәм күрсәтү юлы белән генә җиңеп чыгу мөмкин. Программа, билгеләнгән максатларга ирешү өчен, җирле хакимият органнарының, шулай ук дәүләтнеке булмаган оешмаларның көчләрен берләштерергә һәм оптимальләштерергә мөмкинлек бирәчәк.

### 3. Программаның социаль-икътисадый нәтиҗәлелегенә көтелгән бәя

Программа Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне алга таба үстерү өчен уңай шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын үз эченә ала.

Программаны үтәү түбәндәгеләргә ярдәм итәчәк:

- районда икътисади һәм социаль стабильлекнең иң мөһим элементларыннан берсе буларак, кече һәм урта эшмәкәрлекнең тотрыклы эшчәнлеген барлыкка китерүне стимуллаштыра торган уңай икътисади мохит формалаштыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү темпларын арттыру, эшчәнлек өлкәләрен киңәйтү һәм кече предприятиеләрне икътисади яктан ныгыту;
- җирлек бюджетына салым һәм салым булмаган керемнәр үсеше;
- мәшгульлекнең өстәмә мөмкинлекләре барлыкка килү, кече эшмәкәрлектә эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы дәрәҗәсен күтәрү;
- көндәшлеккә сәләтле продукция, җирле җитештерү хезмәтләре белән товар базарын тулыландыру;
- кече һәм урта эшмәкәрлекнең социаль җаваплылыгы арту.

### 4. Эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре.

Район халкының тормыш-көнкүрешен яхшыртуга юнәлдерелгән тотрыклы икътисади үсешне тәэмин итү максатыннан, эшмәкәрлек эшчәнлегенең өстенлекле төрләре билгеләнде:

- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү;
- халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү;
- транспорт һәм элемтә өлкәсе;
- төзелеш;
- социаль хезмәт күрсәтү өлкәсе.

## 5. 2022 – 2025 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү программасының төп чаралары

| № т/б | Чаралар исемлеге | Нәтиҗә | Финанслау чыганагы | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | **1. Кече һәм урта эшмәкәрлекне нәтиҗәле үстерү өчен, хокукый базаны камилләштерү һәм административ каршылыкларны киметү.** | | | |
| 1 | Эшмәкәрлек өлкәсендә норматив-хокукый база булдыру | Кече эшмәкәрлеккә ярдәм итү буенча нәтиҗәле оештыру чаралары һәм башка чаралар үткәрү | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |
| 2 | Кече эшмәкәрлек үсешенә комачаулый торган административ каршылыкларны бетерү. Контроль-рөхсәт практикасын оптимальләштерү аша дәүләт, кулланучылар һәм эшмәкәрләрнең кызыксынулары туры килүен тәэмин итү | Соратыла торган документларның тулы исемлеген һәм һәр этапта аларны карауның конкрет вакытын күрсәтеп, хезмәтләр эшчәнлегенең төгәл, үтә күренмәле регламентын булдыру, шул исәптән: җир кишәрлекләрен милеккә (арендага) рәсмиләштерү, төзелешкә һәм реконструкцияләүгә проект документларын карау, элмә такталарга һәм реклама мшгълүматларына рөхсәтләр рәсмиләштерү, биналарны торак бинадан булмаган торак бинага һәм киресенчә күчерү, биналарны үзгәртеп коруга рөхсәтләр рәсмиләштерү һ. б. | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |
| 3 | Коррупциягә каршы торуга юнәлдерелгән чараларны камилләштерү турында киңәшләр әзерләү | Коррупциягә каршы үз-үзеңне тотышның уңай тәҗрибәсен гомумиләштерү һәм тарату. Эшмәкәрләрнең коррупция фактларына каршы торуын арттыру, бизнес алып баруның этик дәрәҗәсен күтәрү, кече эшмәкәрлек субъектларының хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | **2. Эшмәкәрлекнең инновацион үсеше (инфраструктураны үстерү, инновацион потенциалны гамәлгә ашыру, яшьләрне инновацион процесска җәлеп итү)** | | | |
| 1 | Яшьләрне эшмәкәрлеккә җәлеп итүгә ярдәм итә торган чаралар комплексын уздыру, шул исәптән укыту, мәгълүмати тәэмин итү, конкурслар һәм ярышлар, ярминкәләр, конференцияләр, бизнес-фестивальләр һ.б. ларны уздыру | Яшьләрне эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү. Яшь белгечләрне эшкә урнаштыру мәсьәләсен өлешчә хәл итү | Җирлек бюджеты акчалары | 2022 ел – 1000 сум 2023 ел – 1000 сум 2024 ел – 1000 сум 2025 ел – 1000 сум. |
| | **3. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс-кредит һәм мөлкәт ярдәме күрсәтү** | | | |
| 1 | Кече эшмәкәрлек субъектларына, инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен, инвесторлар эзләүдә ярдәм итү | Кече эшмәкәрлек субъектларының потенциаль инвесторлар белән хезмәттәшлеген оештыру, кече эшмәкәрлек субъектларының инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен, банк финанславын һәм шәхси капиталны җәлеп итү | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |
| 2 | Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлеге икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатларында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегендә кече эшмәкәрлек субъектларын җир кишәрлекләре, торак булмаган биналар белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү | Шәһәр икътисадының өстенлекле юнәлешләрен үстерү максатларында кече һәм урта предприятиеләрне җир кишәрлекләре, торак булмаган сәүдә һәм җитештерү биналары белән тәэмин итү, районда үткәрелә торган тендерлар, аукционнар турында эшмәкәрләрнең хәбәрдарлыгын арттыру | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |
| 3 | Милли һәм мәдәни үзенчәлекләрдә урта һәм кече эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм | Җирлек бюджеты акчалары | 2022 ел – 500 сум 2023 ел – 500 сум 2024 ел – 500 сум 2025 ел – 500 сум. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә мәгълүмати-консультация ярдәме күрсәтү.** | | | | |
| 1 | Районда кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү һәм аны үстерү өлкәсендә үткәрелә торган чараларны мәгълүмати яктан тәэмин итү | Кече һәм урта бизнес вәкилләренең алдынгы эш тәҗрибәсен системалаштыру һәм тарату. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Зур Сәрдек авыл җирлеге Башкарма комитеты үткәрә торган конкурсларда, күргәзмәләрдә, башка чараларда катнашуга кече эшмәкәрлек субъектларын җәлеп итү | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |
| **5. Эшмәкәрнең уңай имиджын һәм җәмәгатьчелектә кече һәм урта эшмәкәрлек турында уңай фикер формалаштыру** | | | | |
| 1. | Кече эшмәкәрлек субъектларын күргәзмәләрдә, ярминкәләрдә, конкурсларда катнашуга җәлеп итү. | Эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү, эшмәкәрлек эшчәнлегенең иң яхшы субъектлары эшенең алдынгы тәҗрибәсен тарату, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешендә кече һәм урта бизнесның ролен һәм әһәмиятен пропагандалау | Финанслау каралмаган | 2022 – 2025 еллар |